**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОЕЛГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422619 Лаишевский район,
с. Малая Елга, ул.Советская ,д.58,
тел, факс: 8(84378)-3-25-16
E-mail Melg.La@tatar.ru

**КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

422619 Лаеш районы, Кече Елга авылы
Совет урамы , 58 нче йорт
тел, факс: 8(84378)-3-25-16
E-mail Melg.La@tatar.ru

---

2023 елның 31 гыйнвары 6 номер

КАРАР

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2021 елның 15 апрелендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 15 апрелендәге 6 номерлы карары белән расланган» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне үткәрү тәртибенә " түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 3 пунктта "муниципаль программаларның структур элементлары" сүзләрен алып ташларга;

1.2 12 пунктның 2 абзацында «муниципаль программаларның структур элементларына» дигән сүзләрне алып ташларга;

1.3 12 нче пунктның 3 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

" түләүчеләрнең ташламаларга ихтыяҗы, ул ташламалар хокукыннан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия булган түләүчеләр саны, яки 5 ел эчендә түләүчеләрнең гомуми саны нисбәте белән характерлана».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Кече Елга авыл җирлеге**
**Советы рәисе Р.З.Хисамов**